| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>УЛЬЯНКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>УЛЬЯНКОВО АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21.01.2025 Ульянково ав. № 103

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре, муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларга хезмәт өчен түләү күләме нормативлары, айлык һәм башка өстәмә түләүләр һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2018 елның 30 апрелендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре, муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларга хезмәт өчен түләү күләме нормативлары, айлык һәм башка өстәмә түләүләр һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2018 елның 30 апрелендәге 4 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның 2 абзацында «11 498» саннарын «13 990» саннарына алмаштырырга.

1.2. 3нче кушымтаның 1 абзацында «(катлаулылык, киеренкелек, хезмәттә югары казанышлар, махсус эш режимы)» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.3. 5нче кушымтаның 1 абзацын 1 түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәткәрләргә айлык акчалата бүләкләү җирле үзидарә органы җитәкчесенең (муниципаль орган) вазыйфаи окладның 41 процентыннан артмаган күләмдә җирле үзидарә органы (муниципаль орган) җитәкчесенең карары белән билгеләнә, моңа муниципаль хезмәткәрнең җирле үзидарә органнары структурасын муниципаль хезмәт вазыйфасына кече вазыйфаи оклады белән стандартлар кертелүгә бәйле рәвештә билгеләгән очрак очрак керми, ул элек биләгән хезмәт хакыннан кимрәк вазыйфаи оклады белән, шул ук вакытта муниципаль хезмәткәрне акчалата бүләкләү күләмен элек биләгән вазыйфа буенча акчалата түләү күләменә җиткерүне тәэмин итүне исәпкә алып башкарыла.».

1.4. 6 нчы кушымтаны түбәндәге эчтәлекле 2.1., 2.2. пунктлары белән тулыландырырга:

«2.1. Муниципаль хезмәт вазыйфасына муниципаль хезмәткәр билгеләнгәндә, ул элек биләгән вазыйфалар төркеменә караган очракта, биләгән вазыйфа биләгән вазыйфалар төркеме өчен беренче классны чин бирелгәнче, аның оклады күләмен исәпләп чыгару, вазыйфаи окладка процентлы ставкадан чыгып, 3 процентка тигез итеп башкарыла.

2.2. Муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфасына элек биләгән вазыйфаларның түбәнрәк төркеменә караган һәм элек биләгән вазыйфасы буенча аңа класс чины бирелгән очракта, классны чин өчен оклад күләмен исәпләү вазыйфаи окладка процентлы ставкадан чыгып башкарыла, ул 7 процентка тигез.».

1.5. 14 нче кушымтаның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Ульянково авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү фондын формалаштырганда вазыйфаи окладларны түләү өчен җибәрелә торган акчаларның суммасыннан тыш, түләүләр өчен түбәндәге акчалар каралган (бер елга исәпләгәндә 12 вазыйфаи окладтан чыгып):

1) класс чинына айлык өстәмәләр - вазыйфаи окладларның дүрт процентыннан артмаган күләмдә;

2) муниципаль хезмәттә тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмәләр - вазыйфаи окладларның унөч процентыннан артмаган күләмдә;

3) муниципаль хезмәтнең махсус шартлары өчен айлык өстәмәләр - вазыйфаи окладларның биш процентыннан артмаган күләмдә;

4) аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премияләр - вазыйфаи окладларның бер процентыннан артмаган күләмдә;

5) еллык түләүле отпуск биргәндә бер мәртәбә түләнә торган түләү - вазыйфаи окладларның ун процентыннан артмаган күләмдә;

6) айлык акчалата бүләкләү - вазыйфаи окладларның 41 процентыннан артмаган күләмдә;

7) Нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен айлык компенсация түләүләре, юридик эш өчен һәм профильле гыйльми дәрәҗә өчен айлык хезмәт хакына өстәмәләр - вазыйфаи окладларның 2,5 процентыннан артмаган күләмдә.».

1.6. 15 нче кушымтада «15759,00» саннарын «19173,00» саннарына алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» һәм https://ulyan-kaybici.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль районы
Ульянково авыл җирлеге Башлыгы Ф.А.Сундурова